**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**25.03.15** **№ 206-п**

**Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июлендә кабул ителгән “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкаруга вәкаләтле органнар тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында” 636 номерлы карары белән расланган Дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкаруга вәкаләтле органнар, контрольлек буенча чаралар үткәрүгә муниципаль контроль органнары тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү кагыйдәләрен үтәү максатында

БОЕРАМ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә (1 кушымта) (алга таба – Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрү буенча экспертлары реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре (2 кушымта).

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А. Тронин) боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына юлларга.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары – Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә баш дәүләт инспекторы Р.Х. Низамовка йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

1 кушымта
Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының 25.03.2015,
№206-п боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) 2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәргәндә экспертларны аттестацияләү өчен төзелә.

1.2. Нигезләмә Комиссиянең составын һәм эш тәртибен билгели.

1.3. Үз эшчәнлегендә Комиссия федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 10 июлендә кабул ителгән “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) башкаруга вәкаләтле органнар тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында” 636 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

2. Комиссиянең вәкаләтләре

2.1. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәргәндә эксперт статусы алырга дәгъва кылучы физик затларның гаризаларын һәм документларын карап тикшерә;

эксперт статусы алырга дәгъва кылучы физик затларның (алга таба – дәгъва кылучы) квалификациясен тикшеә;

төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәргәндә дәгъва кылучыны эксперт рәвешендә аттестацияләү турында яисә аттестацияләүдән баш тарту турында карарлар кабул итә.

2.2. Комиссия әгъзалары Комиссиянең составын, аның эш һәм карарлар кабул итү тәртибен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Комиссия рәисе раславына кертү хокукына ия.

2.3. Кабул ителүче карарларның нигезле һәм объектив булуы өчен Комиссия җаваплылы була.

3. Комиссиянең составы һәм эш тәртибе

3.1. Комиссия Министрлык тарафыннан 7 кеше күләмендә төзелә.

3.2. Комиссиянең составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, аның урынбасары, Комиссия сәркатибе һәм 4 Комиссия әгъзасы керә.

3.3. Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә, аның утырышларында рәислек итә, Комиссия эшен оештыра, хәл иткеч тавыш бирү хокукы белән Комиссиядә тавыш бирүдә катнаша, Комиссия карарларының беркетмәләренә имза сала.

Комиссиянең рәисе булмаганда аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

3.4. Комиссия сәркатибе Комиссия эшләрен алып бара, Комиссия утырышында көн тәртибе турында җиткерә, Комиссия карарларының беркетмәләрен рәсмиләштерә.

3.5. Квалификация имтиханнары үткәрелә торган утырышлар Комиссиянең төп эшләү рәвеше булып тора.

3.6. Комиссия аттестация турында гаризалар кергән көннән башлап 3 айдан да соңга калмыйча утырышлар үткәрә.

3.7. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. Әгәр Комиссия утырышында аның әгъзаларының яртысыннан артык өлеше катнашса, Комиссия үз компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү хокукына ия. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәл иткеч санала.

3.8. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия беркетмәсе утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия утырышын үткәргән көнне Комиссия рәисе тарафыннан таныклана.

4. Квалификация имтиханын үткәрү тәртибе

4.1. Аттестация узу өчен дәгъва кылучы Министрлыкка әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегендә билгеләнгән критерийларга туры килүне раслаучы түбәндәге документларны тапшыра:

а) әлеге Нигезләмәгә карата кушымта рәвешендә аттестацияләү турында гариза;

б) белем алганлыкны раслый торган документларның күчермәләре, шулай ук (булган очракта) фәнни дәрәҗәне раслый торган документларның күчермәләре, аттестатларның, сертификатларның, таныклыкларның күчермәләре;

в) паспортның яисә шәхесне таныклый торган башка документның күчермәсе;

г) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яки эш стажы барлыгын раслый торган башка документлар;

д) өстәмә белем хезмәтләре алуны раслый торган башка документларның күчермәләре.

4.2. Аттестация турындагы гариза һәм аңа теркәлә торган документларның күчермәләре эксперт аттестациясен алуга дәгъва кылучы граждан тарафыннан Министрлыкка шәхсән тапшырыла яисә кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән почта аша заказлы хат итеп яисә “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация

челтәре аша гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.3. Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән барлык зарури документларны тапшырган һәм Нигезләмәнең 5.1.1, 5.1.2, 5.1.3 пунктларында каралган аттестация критерийларына туры килүче дәгъва кылучылар квалификация имтиханнарына кертелә.

4.4. Дәгъва кылучы тапшырган барлык документларны һәм белешмәләрне карап тикшерү нәтиҗәсендә Министрлык тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) дәгъва кылучыны аттестацияләүдән баш тарту турында – мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы таләпләргә туры килмәве һәм (яки) гражданның аттестация критерийларына туры килмәве;

б) дәгъва кылучыны квалификация имтиханына кертү турында.

4.5. Комиссия дәгъва кылучыга әлеге Нигезләмәнең 4.4 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителү хакында мондый карарны кабул итү көненнән соң 5 эш көне дәвамында кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән почта аша заказлы хат җибәрү юлы белән яисә “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә хәбәр итә.

4.6. Квалификация имтиханы әңгәмә рәвешендә үткәрелә. Карап тикшерү нәтиҗәсендә Комиссия нигезле карар кабул итә.

4.7. Дәгъва кылучының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Россия Федерациясе законнары өлкәсендәге актларга, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге профессиональ эш дәрәҗәсенә карата белемнәре тикшерелә.

4.8. Квалификация имтиханының нәтиҗәсе Комиссия беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча дәгъва кылучының аттестация критерийларына туры килүе турында карар кабул ителү нәтиҗәсендә аның аттестацияләнүе турында яисә квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча аның аттестация критерийларына туры килмәве нигезендә яки дәгъва кылучы квалификация имтиханына килмәсә, дәгъва кылучыны аттестацияләүдән баш тарту турында боерык чыгару өчен нигез булып тора.

4.9. Министрлык боерыгының күчермәсе карар кабул ителгән көннән соң 3 эш көне дәвамында дәгъва кылучыга бирелә яисә кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән почта аша заказлы хат итеп, яисә “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.10. Экспертлар әлеге Нигезләмәнең 4.1-4.7 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәр 5 ел саен яңадан аттестацияләнергә тиеш.

4.11. Экспертлар турындагы белешмәләр Министрлыкның төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чараларны үткәргәндә экспертлар реестрына кертелә.

4.12. Министрлыкның һәм аның вазифаи затларының карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) суд тәртибендә, шулай ук Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне оештыру турындагы законнары нигезендә судка кадәрге тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

## 5. Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чараларны үткәргәндә экспертларны аттестацияләү критерийлары.

5.1. Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чараларны үткәргәндә эксперт аттестаты алуга дәгъва кылучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

5.1.1. Эксперт булырга дәгъва кылучы шәхси эшмәкәр, гамәлгә куючы, директор, аттестацияләүгә карата игълан ителгән эшчәнлек өлкәсендә эшчәнлек башкаручы предприятиенең вазифаи заты булырга тиеш түгел.

5.1.2. Дәгъва кылучы түбәндәгеләргә ия булырга тиеш:

а) югары белем (аттестацияләүгә карата игълан ителгән эшчәнлек өлкәсендә);

б) әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә кимендә биш еллык эш стажы;

в) әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә эш тәҗрибәсе һәм профессиональ күнекмәләр.

5.1.3. Дәгъва кылучы Россия Федерациясенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы законнары өлкәсендә белемнәргә ия булырга тиеш.

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү комиссиясе турында нигезләмәгә карата кушымта

Татарстан Республикасының экология һәм табигый ресурслар министрына

_______________________________________________

(кемнән)___________________________________

_______________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А., туган көне,

_______________________________________________

ИНН,

____________________________________________

шәхесен таныклый торган документ белешмәләре,

_____________________________________________

яшәгән урынының адресы,

____________________________________________

телефон номеры, электрон почта адресы)

Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәргәндә экспертны аттестацияләү турында

гариза

Мине төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәргәндә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы эксперты аттестациясен алу өчен квалификация имтиханына кертүне сорыйм.

Документлар теркәлә: ___________________________________________________

(документлар исемлеге)

______________________ ___________________

(дата) (имза)

2 кушымта
Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының 25.03.2015,
№206-п боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрү буенча экспертлары реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрү буенча экспертлары реестрын (алга таба – Реестр) формалаштыру һәм алып бару тәртибен, шул исәптән Реестрга кертелә торган белешмәләрнең составын һәм Реестрдан белешмәләр бирү тәртибен билгели.

1.2. Реестрны формалаштыруны һәм алып баруны тәэмин итү мәгълүмати системаларны үстерү һәм мәгълүматлаштыру бүлеге (Л.Н. Гыйззәтуллина) тарафыннан башкарыла.

1.3. Реестр Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеге буенча чаралар үткәрү буенча экспертлары турындагы белешмәләрне электрон рәвештә үз эченә ала.

1.4. Реестр Министрлыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

2. Экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе

2.1. Министрлыкның экспертны аттестацияләү турындагы, шулай ук эксперт аттестациясенең гамәле туктатылу турындагы карары экспертлар турындагы белешмәләрне Реестрга кертү өчен нигез булып тора.

2.2. Реестр (рәвеше бирелә) түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

а) язуның теркәлү номеры;

б) эксперт турындагы белешмәләрне Реестрга кертү датасы;

в) физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), аның яшәгән урынының адресы, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре, телефон номеры һәм электрон почта адресы (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры;

г) аттестацияләү турындагы карарның номеры һәм кабул ителү датасы;

д) эксперт аттестациясенең гамәле туктатылу турындагы карарның номеры һәм кабул ителү датасы;

е) экспертның квалификациясе, шул исәптән квалификациясен үстерү, профессиональ яктан яңадан белем алуы турында белешмәләр;

ж) экспертның белеме һәм эш тәҗрибәсе турында белешмәләр;

з) эксперт эшли торган яисә хезмәтләр күрсәтү максатында аның белән хезмәттәшлек итүче оешманың исеме һәм урнашкан урыны.

2.3. Мәгълүмати системаларны үстерү һәм мәгълүматлаштыру бүлеге (Л.Н. Гыйззәтуллина) 3 эш көненнән артып китмәгән вакыт эчендә Реестрга белешмәләр кертә, түбәндәге көннән соң:

а) аттестация турында, аттестациянең гамәле туктатылу турында карар кабул ителгәч;

б) Реестрдагы белешмәләргә үзгәрешләр кертелгәч.

2.4. Реестрның рәвеше:

| № п/п | Аталышы | Белешмәләр |
|---|---|---|
| 1 | язуның теркәлү номеры | |
| 2 | эксперт турында белешмәләрне реестрга кертү датасы | |
| 3 | физик затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) | |
| 4 | аның яшәгән урынының адресы | |
| 5 | шәхесен таныклаучы документ белешмәләре | |
| 6 | телефон номеры һәм электрон почта адресы (булган очракта) | |
| 7 | салым түләүченең идентификация номеры | |
| 8 | аттестация турындагы карарның номеры һәм кабул ителү датасы | |
| 9 | эксперт аттестациясенең гамәле туктатылу турындагы карарның номеры һәм кабул ителү датасы | |
| 10 | экспертның квалификациясе, шул исәптән квалификацияне үстерү, профессиональ яктан яңадан белем алуы турында белешмәләр | Түбәндәгеләр күрсәтелә: белем бирү учреждениесенең аталышы; белем алу турында документның номеры һәм бирелү датасы; бирелгән белгечлекнең, квалификациянең аталышы; дәгъва кылучы күрсәтелгән вазифада эшләгән оешмаларның исемлеге |
| 11 | эксперт эшли торган яисә хезмәтләр күрсәтү максатында аның белән хезмәттәшлек итүче оешманың исеме һәм урнашкан урыны | |

3. Реестрда булган белешмәләрне бирү тәртибе

3.1. Реестрда булган белешмәләр дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар тарафыннан танышу өчен ачык булып тора, алардан файдалану Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүматка карый торган белешмәләрдән кала.

3.2. Реестрда булган белешмәләрдән файдалану мөмкинлеге күрсәтелгән белешмәләрнең Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми

сайтында ачык мәгълүматлар рәвешендә урнаштыру юлы белән тәэмин ителә, алардан файдалану Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүматка карый торган белешмәләрдән кала.

3.3. Реестрда булган белешмәләр бушлай бирелә.